ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

28.11.2014 Казан ш. № 5-28/тэ

***“Урыссу ГРЭСы ТДК” ЯАҖ кулланучыларга бирә торган җылылык энергиясенә 2015 елга тарифлар билгеләү турында***

“Җылылык белән тәэмин итү турындагы” 27.07.2010 ел № 190-ФЗ федераль законына, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәяләр билгеләү турындагы” 22.10.2010 ел № 1075 карарына, Тарифлар буенча федераль службаның “Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә көйләүле бәяләрне (тарифларны) исәпләү буенча методик күрсәтмәләрне раслау турындагы” 13.06.2013 № 760-э һәм “Җылылык белән тәэмин итү оешмалары кулланучыларга бирә торган җылылык энергиясенә (егәрлеккә) тарифларның Россия Федерациясе субъектлары буенча уртача соң чик максималь кимәлләрен 2015 елга билгеләү турындагы” 11.10.2014 № 227-э/3 боерыкларына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 15.06.2010 № 468 карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында кагыйдәләренә ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР ИТӘ:

1. “Урыссу ГРЭСы ТДК” ЯАҖ кулланучыларга бирә торган җылылык энергиясенә (егәрлеккә) календарь буенча бүленгән тарифларны шушы карарның кушымтасына ярашлы рәвештә билгеләргә.

2. Шушы карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2015 елның 1 январеннан 2015 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Шушы карар аны рәсми игълан итү көненнән соң ун көн үткәч үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Тарифларбуенча
Дәүләт комитеты Рәисе М.Р. Зарипов

Татарстан Республикасының
Тарифлар буенча дәүләт
комитетының 28.11.2014 № 5-28/тэ
карарына кушымта

## “Урыссу ГРЭСы ТДК” ЯАҖ кулланучыларга бирә торган җылылык энергиясенә 2015 елга календарь буенча бүленгән тарифлар

| Т. № | Муниципаль берәмлек, көйләнүче оешма атамасы, тариф төре | Ел | Су | Алынган парның басымы | | | | Үткен һәм редукция-ләнгән пар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 1,2-2,5 кг/см$^2$ | 2,5-7,0 кг/см$^2$ | 7,0-13,0 кг/см$^2$ | > 13,0 кг/см$^2$ | |
| | Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы бистәсе | | | | | | | |
| 1. | “Урыссу ГРЭСы ТДК” ЯАҖ | | | | | | | |
| 1.1 | Кулланучылар өчен, тарифлар тоташтыру схемасы буенча дифферентланмаган очракта | | | | | | | |
| | Бер ставкалы тариф, сум/Гкал | 01.01.2015–30.06.2015 | 1467,37 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2015–31.12.2015 | 1569,04 | - | - | - | - | - |
| 1.2 | Халык (тарифлар НДСны исәплләп күрсәтелгән) | | | | | | | |
| | Бер ставкалы тариф, сум/Гкал | 01.01.2015–30.06.2015 | 1731,50 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2015–31.12.2015 | 1851,47 | - | - | - | - | - |

Татарстан Республикасытарифларбуенча
Дәүләт комитеты, Тарифларбуенчакарарларны
кабул итү, оештурыһәмҗайга салу бүлеге